МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.04.2023 Казан ш № 298

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.06.2019 №484, 16.08.2019 №624, 14.11.2019 №1023, 18.06.2020 №436, 27.07.2020 №536, 24.09.2020 №669, 18.12.2020 №876, 02.06.2021 №388, 20.09.2021 №670, 15.11.2021 №837, 28.02.2022 №134 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Заripова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау
министрлыгының 2023 елның
19 апрелендәге 298 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
кертелә торган үзгәрешләр

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затлар, качаклар, әгәр аларның тормыш шартларын начарлатучы яки начарлатырга мөмкин булган түбәндәге шартлар булса:

1) авыру, травма алу, яшенә яки инвалид булуына бәйле рәвештә тулысынча яки өлешчә сәләтне яки үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, тормыштагы төп ихтыяҗларны тәэмин итү мөмкинлеген югалту;

2) гаиләдә даими рәвештә ятлар каравына мохтаҗ булган инвалид яки инвалидлар, шул исәптән инвалид бала яки инвалид балалар булуы;

3) социаль яраклашуда кыенлыклар кичерүче бала яки балалар (шул исәптән опекада, попечительлектә торучы) булуы;

4) инвалидны, баланы, балаларны карауны (шул исәптән вакытлыча) тәэмин итү мөмкинлеге булмау, шулай ук аларга карата тәрбия булмавы;

5) гаилә эчендә, шул исәптән наркотик яки алкоголь бәйлелегендәге затлар белән, комарлы уеннарга һәвәслеге булган затлар белән, психик тайпылышлардан интегүче затлар белән, низаг булуы, гаиләдә ирексезләү булуы;

6) билгеле бер яшәү урынының булмавы, шул исәптән егерме өч яшенә җитмәгән һәм ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмада торуын тәмамламаган затның;

7) эш һәм яшәү өчен акча булмау;

8) Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актлары нигезендә гражданнарның тормыш шартларын начарлатучы яки начарлатырга сәләтле дип танылган башка шартларның булуы (аерым алганда, гадәттән тыш хәлләр, кораллы милләтара (этникара) низаглар нәтиҗәләре).

Мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап аларның законлы вәкилләре, башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлү турындагы шарт билгеле бер яшәү урыны булмаган затларга, шулай ук, законнарда каралган очракларда, балигълык яшенә җитмәгән затларга кагылмый.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

1.4 - 1.6 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы

2.2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнарында (шәһәр округларында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Министрлыкның территориаль органы) тарафыннан;

Министрлык карамагында торган, гражданнарны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тануга һәм Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлеге территорияләрендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзүгә вәкаләтләр бирелгән оешма (алга таба – вәкаләтле оешма) тарафыннан.

Вәкаләтле оешмаларның исемлеге Министрлык тарафыннан раслана.

Министрлыкның территориаль органнары тарафыннан гражданинның социаль хезмәтләр күрсәтүгә һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы проектын әзерләүдә индивидуаль ихтыяҗын билгеләүдә Министрлыкка караган, әлеге функцияләр йөкләнгән «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурслар үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Учреждение) катнаша.

2.2.2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын (алга таба – индивидуаль программа) төзү;

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану» дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар);

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.2. Нәтиҗә әлеге Регламентның 8 нче кушымтасындагы форма буенча рәсмиләштерелә.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

Министрлыкның территориаль органы, вәкаләтле оешма исеме;

гаризаның номеры һәм датасы;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза булуы турында мәгълүмат.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза булуы турында мәгълүмат.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.4. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар мөрәҗәгать итүчегә ул сайлаган ысул буенча бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталындагы (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) һәм «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба –

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) шәхси кабинетына җибәреп.

Әгәр гаризада хәбәр итү ысулы билгеләнмәгән булса, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән ысул белән җибәрелә.

мөрәҗәгать итүчегә  индивидуаль программа кулына тапшырыла.

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы

2.4.1. Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән бирелгән булса, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) тарафыннан әлеге Регламентның 2, 3, 4 нче кушымталарында күрсәтелгән кирәкле барлык документлар белән гариза теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә кабул ителә.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша җибәрелеп тапшырылган булса, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) тарафыннан әлеге Регламентның 2, 3, 4 нче кушымталарында күрсәтелгән кирәкле барлык документлар белән гариза теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә кабул ителә.

Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән булса, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) тарафыннан әлеге Регламентның 2, 3, 4 нче кушымталарында күрсәтелгән кирәкле барлык документлар белән гариза теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә кабул ителә.

2.4.2. Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кичекмәстән кабул ителә.

2.4.3. Гражданинга индивидуаль программа төзү гариза бирелгән көннән алып 10 эш көненнән дә ким булмаган вакытта гамәлгә ашырыла.

Билгеле бер чорга социаль хезмәтләр күрсәтү индивидуаль программаны төземичә гамәлгә ашырыла.

2.4.4. Мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында кабул ителгән карар, индивидуаль программаны төзү көне һәм урыны турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү гариза бирелгән көннән башлап биш эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы яки электрон почта адресы буенча, Республика порталында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә) гамәлгә ашырыла.

2.4.5. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану, индивидуаль программа төзү турында яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында белдерү җибәрелгән мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гражданинның социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар күчермәсен, индивидуаль программа нөсхәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) яки муниципаль хезмәткәрләр, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза бирә:

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза формасын раслау турында» 2014 елның 28 мартындагы 159н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча кәгазьдә;

Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

2.6.2. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентка 2 нче кушымтадагы исемлек буенча да документлар тапшыра.

Стационар формада социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентка 3 нче кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра.

Ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентка 4 нче кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра.

Чоры билгеле социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентка 5 нче кушымтадагы исемлек буенча да документлар тапшыра.

2.6.3. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә дә тапшырыла (җибәрелә) ала:

шәхсән;

почта аша почта юлламасы белән;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

Бердәм портал аша электрон формада.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре (алга таба – «Интернет» челтәре) аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гариза кәгазенең электрон формасы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында http://mtsz.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырылган.

2.6.4. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча әлеге Регламентка 6 нчы кушымта нигезендәге исемлек буенча документлар алына.

2.6.5. мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм Регламентның 2.6.1 һәм 2.6.2 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүче паспортының чын булуын раслау турындагы белешмәләр алына.

2.6.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гаризаны кабул итүдән баш тартуга нигез була алмый.

Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезе:

гамәлдәге сроклары беткән документлар һәм мәгълүматлар тапшыру, документларда билгеләнгән тәртиптә танылканмаган чистартылган, өстәп язылган, сүзләре сызылган һәм төзәтмәләр кертелгән урыннар булу;

документларда хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

хезмәт күрсәтү турындагы гаризаның һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада тапшырылуы;

гариза формасындагы, шул исәптән Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның проактив формасындагы кырларны тулылысынча тутырмау.

хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны да тапшырмау яки тулы күләмдә тапшырмау;

63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең исемлеге тулы булып тора.

2.7.3. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

гражданинда аның яшәеш шартларын начарайта яки начарайтырга мөмкин булган шартларның булмавы;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документларның формасы һәм эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килмәве;

хезмәт күрсәтү турындагы гаризадагы мәгълүматлар һәм ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алынган мәгълүматлар арасында каршылыклар булуы;

социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган медицина каршылыкларының ачыклануы;

гражданинның социаль хезмәтләр күрсәтүдән язмача баш тартуы;

кушымта итеп тапшырылган документларда күрсәтелгән, каршылыклы мәгълүматларның булуы.

2.8.2. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.10.1. Мөрәҗәгать итүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен кабул итүне көтү буенча чират билгеләнмәгән.

### 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Шәхсән мөрәҗәгат иткән очракта, гариза һәм документлар алынган көнне.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада алынган гаризалар һәм документлар ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

2.11.3. Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза бирелгән көнне Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы, Бердәм порталдагы шәхси кабинетта һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелүен раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәү номеры һәм тапшыру датасы күрсәтелгән була.

### 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз үтеп керә алу максатларында, түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән хезмәттән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, хезмәтләр күрсәтелә торган объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.3. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) Министрлыкның территориаль органы (учреждение, вәкаләтле оешма) хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, хезмәт күрсәтү;

в) хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, аларга хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.4. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәтенең сыйфаты һәм һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:

Министрлыкның территориаль органы, учреждение, вәкаләтле оешма биналарының җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

Министрлыкның территориаль органы, учреждение, вәкаләтле оешма белгечләре тарафыннан инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

Министрлыкның территориаль органы (учреждение, вәкаләтле оешма) белгечләре тарафыннан Регламент бозылуга карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның территориаль органы (учреждение, вәкаләтле оешма) белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

гаризаларны һәм документларны почта, шул исәптән электрон почта аша, Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргәндә – турыдан-туры хезмәттәшлек таләп ителми;

әгәр гариза белән документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.4. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы белгечләр белән бер тапкыр үзара хезмәттәшлек итүенең вакыты буенча озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында алынырга мөмкин.

2.13.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан, Бердәм порталдан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм документларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлыкның территориаль органы, учреждение, вәкаләтле оешма белгече, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.14.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне Министрлыкның территориаль органына кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша, Министрлыкның территориаль органының телефон номеры аша телефон элемтәсе аша гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүчегә Министрлыкның территориаль органында билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә буш булган теләсә нинди кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

(фамилиясе, исемен һәм атасының исемен (булган очракта))

телефон номеры;

электрон почта адресы (ихтыяры буенча);

кабул итүнең теләнгән датасы һәм вакыты.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында  зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.4. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша гариза биргәндә гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү электрон формада җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.»;

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәгечә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту турында) турында карар әзерләү;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүчегә тапшыру яки дәүләт хезмәте нәтиҗәсен почта буенча җибәрү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны (алга таба – техник хата) төзәтү.»;

3.2.3, 3.2.4 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү, мәгълүматлар алу

3.3.1. Рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның территориаль органында (вәкаләтле оешмада) теркәлгән гаризасы тора.

Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече электрон формада вәкаләтле органнардан әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында күрсәтелгән мәгълүматны ала.

Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза һәм документлар Учреждениегә (вәкаләтле оешмага) алынган көннән башлап бер эш көне эчендә Учреждениенең (вәкаләтле оешма) белгече тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле, гражданин (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) тарафыннан тапшырылмаган, әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр соратыла.

Ведомствоара мәгълүмати мөрәҗәгать мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган мәгълүматлар.

Учреждениедә (вәкаләтле оешмада) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, учреждение (вәкаләтле оешма)

белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша вәкаләтле органнарга әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында күрсәтелгән мәгълүматларны бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

3.3.2. Ведомствоара бәйләнештә катнаша торган вәкаләтле орган яки оешма Учреждениегә (вәкаләтле оешмага) сорала торган белешмәләрне бирә.

Ведомствоара гаризаны әзерләү һәм җибәрү срогы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны теркәгән көннән башлап бер эш көне тәшкил итә.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгать буенча шул белешмәләр булган органнар тарафыннан белешмәләрне бирү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән артмаска тиеш.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара гарызнамәләргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара гарызнамә алынган көннән башлап биш эш көненнән (ике эш көне - дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алганда) артмаска тиеш.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Тапшырылган мәгълүматлар административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

3.4 пунктның дүртенче абзацында «социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.7.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.7.1. Техник хатаны төзәтү мөрәҗәгать итүче тарафыннан, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге

Регламентның 9 нчы кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның гаризаларын теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 7 нче кушымтасы);

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту турында) турында карар проектын электрон рәвештә үзгәртеп рәсмиләштерә;

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту турында) турында электрон формада яңадан рәсмиләштерелгән карар проектын Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) җитәкчесенә имза куюга юнәлтелгән гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту турында) турында электрон формада яңадан рәсмиләштерелгән карар проекты.»;

4 бүлектә:

4 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламент үтәлешен тикшереп тору формалары»;

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.»;

5 бүлектә:

5 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктның бишенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың) вазыйфаи затының (хезмәткәренең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың) дәүләт хезмәткәренең (хезмәткәренең), җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Шикаять почта аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.»;

5.4 пунктның икенче абзацында «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.5 пунктның 1, 3, 4 пунктчаларында «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.6.1 пунктта «КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләрен төшереп калдырырга;

Регламентка 2 нче кушымтада:

3 пунктның «Документлар исемлеге» графасында «Карар» сүзен «Карар күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның «Документлар исемлеге» графасында «Карар» сүзен «Карар күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «6. | Гражданинга яисә социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыга социаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тарту ихтималлыгы булган медицина каршылыклар булуы турында яисә мондый медицина каршылыкларының булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе | медицина оешмалары | белешмәдә күрсәтелүче »; |

Регламентка 3 нче кушымтада:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «6. | Гражданинның сәламәтлек торышы турында медицина оешмасы белешмәсе* | медицина оешмалары | белешмәдә күрсәтелүче»; |

7 пунктның «Документлар исемлеге» графасында «Карар» сүзен «Карар күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның «Документлар исемлеге» графасында «Карар» сүзен «Карар күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктны көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле «*» астөшермә өстәргә:

«*- гражданнарны өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда, психик тайпылышлары булган гражданнар, шул исәптән балалар өчен билгеләнгән интернат-йортларда социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип таныганда, гражданинның сәламәтлеге турында медицина оешмасы белешмәсендә чит кеше каравына мохтаҗлык күрсәтелә.»;

Регламентка 4 нче кушымтада:

3 пунктның «Документлар исемлеге» графасында «Карар» сүзен «Карар күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның «Документлар исемлеге» графасында «Карар» сүзен «Карар күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «6. | Гражданинга яисә социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыга социаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тарту ихтималлыгы булган медицина каршылыклар | медицина оешмалары | белешмәдә күрсәтелүче»; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | булуы турында яисә мондый медицина каршылыкларының булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе | | |

Регламентка 6 нче кушымтада:

12 пунктның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды»;

түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «13. | Гариза биргән айдан алдагы 12 айда керемнәр турында белешмәләр («Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль законның 31 статьясындагы беренче өлешендә китерелгән категорияләргә караган гражданнар өчен тапшырылмый) (яшәеш шартларын атикшерү акты китерелгәндә) | керемнәрнең булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) бирү вәкаләте бирелгән органнар (оешмалар) | керемнәрнең булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) бирү вәкаләте бирелгән органнар (оешмалар)»; |

Регламентка 8 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Формасы

Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) исеме

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар

№_______________ _________________________

______________ №______ гариза һәм аңа теркәлгән документлар нигезендә, әлеге гр. тарафыннан тапшырылган

_____________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

кая

_____________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле орган исеме)

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль законның 15 статьясы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 908 номерлы карары белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү тәртибе нигезендә гр. ____________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы)

социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип:

____________________________________________________________

(социаль хезмәт күрсәтү формасын күрсәтергә)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ______________________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсе (бүлеге) җитәкчесе (Вәкаләтле оешма директоры)

______________ ____________________________

(имза) (тулы имза)

Социаль хезмәтләр күрсәтү программасын (алга таба – индивидуаль программа) төзүдә ______________________________ адресы буенча ______ катнашырга хокуклы.

(дата)

адресы ____________________________________________________________.

(учреждение, вәкаләтле оешма адресы)

Индивидуаль программаны алу өчен монда килергә кирәк

____________________________________________________________

(учреждениенең, вәкаләтле оешманың исеме)

_________________ әлеге адрес буенча:

____________________________________________________________

(индивидуаль программаны бирү көне) (учреждениенең, вәкаләтле оешманың адресы)

Мөһер урыны

«_____________» «_____________» Электрон имза турында белешмәләр

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану» дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

№__________, _________________

_____________ №______ гариза һәм аңа теркәлгән документлар нигезендә, әлеге гр. тарафыннан тапшырылган

______________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

кая __________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле орган исеме)

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 908 номерлы карары белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү тәртибе нигезендә гр.

______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы)

социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартырга:

______________________________________________________________________

(социаль хезмәт күрсәтү формасын күрсәтергә)

түбәндәге нигезләр буенча:_______________________________________________

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

____________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Сез, күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергәннән соң, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бу баш тартуга шикаять җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин

___________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле орган исеме)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ________________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсе (бүлеге) җитәкчесе (Вәкаләтле оешма директоры)

_________________ _________________________

(имза) (тулы имза)

Мөһер урыны

«______________» «_____________» Электрон имза турында белешмәләр

Документларны кабул итүдән баш тарту турында карар

Әлеге гр. тапшырган гариза һәм документлар нигезендә

__________________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

кая

______________________________________________________________

(дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле орган исеме)

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 908 номерлы карары белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү тәртибе нигезендә

гр.__________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы)

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартырга, әлеге нигезләр буенча: _________________________________

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

_______________________________________________________________

(документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Сез, күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергәннән соң, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бу баш тартуга шикаять җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин

_________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле орган исеме)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ______________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсе (бүлеге) җитәкчесе (Вәкаләтле оешма директоры)

________________ ______________________________

(имза) (тулы имза)

Мөһер урыны

«____________» «____________» Электрон имза турында белешмәләр»;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.